ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.12.2017 Казан ш. № 10-50/кс

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Генерацияләү компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте филиалы – «Балкыш» шифаханә-профилакториесе өчен агынты суларны транспортлауга 2017-2019 елларга тарифлар билгеләү турында» 30.11.2016 № 10-25/кс карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы, «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә җайга салынулы тарифлар билгеләү регламентын раслау турында» 2014 елның 16 июлендәге 1154-э номерлы боерыклары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, 2018-2019 елларга агынты суларны транспортлауга дәвамлы тарифларга һәм 2018-2019 елларга җайга салынучы оешманың зарури тулай табышына үзгәрешләр кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Генерацияләү компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте филиалы – «Балкыш» шифаханә-профилакториесе өчен агынты суларны транспортлауга 2017-2019 елларга тарифлар билгеләү турында» 30.11.2016 № 10-25/кс карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Генерацияләү компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте» аталышындагы сүзләрне һәм алга таба текст буенча тиешле килеш кушымчаларында кулланып, «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте» сүзләренә алмаштырырга;

1 кушымтаны шушы карарның 1 нче кушымтасы буенча төзәтелгән яңа эчтәлегендә бәян итәргә;

2 кушымтаны шушы карарның 2 нче кушымтасы буенча төзәтелгән яңа эчтәлегендә бәян итәргә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 01.12.2017 № 10-50/кс карарына
1 нче кушымта
«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 30.11.2016 № 10-25/кс карарына
1 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы, «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте филиалы – «Балкыш» шифаханә-профилакториесе өчен агынты суларны транспортлауга 2017-2019 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Агынты суларны транспортлаган өчен тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2017 ел | | 2018 ел | | 2019 ел | |
| | | 01.01.2017 башлап 30.06.2017 кадәр | 01.07.2017 башлап 31.12.2017 кадәр | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр |
| | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге | | | | | | |
| 1 | «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте | | | | | | |
| 1.1 | «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте филиалы – «Балкыш» шифаханә-профилакториесе (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелде) | 10,26 | 10,69 | 10,63 | 10,63 | 10,63 | 11,06» |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 01.12.2017 № 10-50/кс карарына 2 нче кушымта
«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 30.11.2016 № 10-25/кс карарына 2 нче кушымта

## Салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте филиалы – «Балкыш» шифаханә-профилакториесе өчен 2017-2019 елларга агынты суларны транспортлауга тарифларны җайга салуның дәвамлы параметрлары

| № п/п | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су бүлүне гамәлгә ашыручы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергия саклау күрсәткечләре һәм энергетика нәтиҗәлелеге | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Су югалту дәрәҗәсе | электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте | | | | | | |
| 1.1 | «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте филиалы – «Балкыш» шифаханә-профилакториесе | | | | | | |
| 1.1.1 | Агынты суларны транспортлау | 2017 | 161,83 | 1 | - | - | 0,33 |
| | | 2018 | 166,62 | 1 | - | - | 0,33 |
| | | 2019 | 171,55 | 1 | - | - | 0,33» |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге